**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” март 2024 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Олы Бәрәзә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (вак таш сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); Олы Бәрәзә авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).”.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пунктында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Фатыхова А.В.